**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5995**
**13.11.2020**

Башкарма комитетның «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6977 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 6977 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктны өстәргә:

«1.1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Су хуҗалыгы» 04.06 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына, 2019 елда – 230,1 мең сум, 2020 елда – 248,8 мең сум, 2021 елда – 248,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау системасын камилләштерү һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү» муниципаль программасында:

- 1 бүлекнең 8 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль бюджет | 230,1 | 248,80 | 248,80 | 727,7 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 230,1 | 248,80 | 248,80 | 727,7 |

- 3 бүлекнең 5 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Гидротехник корылмаларның эксплуатация ышанычлылыгын күтәрү буенча чаралар | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | Гидротехник корылмаларны авариясез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 230,10 | 248,80 | 248,80 |

2. 6 нчы «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен 727,7 мең сум күләмендә шәһәр бюджеты акчалары тәшкил итә, шул исәптән:

2019 ел – 230,1 мең сум;

2020 ел – 248,80 мең сум;

2021 ел – 248,80 мең сум.

Программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр кимегәндә яки артканда, программаны башкаручы чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

Программаны финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм билгеләнгән тәртиптә аңа төгәллекләр кертелергә тиеш.».

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов